| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.07.2020 Казан ш. № 21-41-129

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты средстволарының баш администраторларына карата финанс менеджменты сыйфатына мониторинг үткәрү тәртибен раслау турында” 23.10.2019 ел, № 21-41-249 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

БОЕРЫК Б И Р Ә М:

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты средстволарының баш администраторларына карата финанс менеджменты сыйфатына мониторинг үткәрү тәртибен раслау турында” 23.10.2019 ел, № 21-41-249 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты средстволарының баш администраторларына карата финанс менеджменты сыйфатына мониторинг үткәрү тәртибенең 2 пунктында “контроль” сүзен “аудит” сүзенә алыштырырга;

Әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты средстволарының баш администраторларына карата финанс менеджменты сыйфатына мониторинг үткәрү тәртибенә №1 кушымтаның 5.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «5.4. Бюджет средстволары баш администраторының эчке финанс | | % | | 35 | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| аудитын оештыру һәм хәл итүнең сыйфаты | | | | | | |
| 5.4.1. Эчке финанс аудитын оештыруның сыйфаты <1> | Эчке финанс аудитын оештыруның сыйфатына карата таләпләр:<br>1) Бюджет средстволары баш администраторының эчке финанс аудитын хәл кылуны тәэмин итүче ведомство актына ия булуы һәм аның эчке финанс аудиты федераль стандартлары нигезләмәләренә туры килүе;<br>2)бюджет средстволары баш администраторы җитәкчесенең эчке финанс аудитын оештыру турында карарына ия булуы. | % | Бу пункт таләпләре тулысынча үтәлгән | 5 | 50 | Билгеләнгән таләпләрне үтәү финанс менеджменты сыйфатын яхшыртуга ярдәм итәрдәй уңай фактор булып тора.<br>Күрсәткеч һәр ел саен исәпләп чыгарыла. |
| | | | Бу пункт таләпләре тулысынча ук үтәлмәгән | 2,5 | | |
| | | | Бу пункт таләпләре үтәлмәгән | 0 | | |
| 5.4.2. Аудиторлык чараларын планлаштыру һәм үткәрүнең, аудиторлык чараларын үткәрү нәтиҗәләрен тормышка ашыруның | Аудиторлык чараларын планлаштыру һәм үткәрүнең, аудиторлык чараларын үткәрү нәтиҗәләрен тормышка ашыруның сыйфатына карата таләпләр: | % | Бу пункт таләпләре тулысынча үтәлгән | 5 | 50 | Билгеләнгән таләпләрне үтәү финанс менеджменты сыйфатын яхшыртуга ярдәм итәрдәй уңай фактор булып тора.<br>Күрсәткеч һәр ел саен исәпләп |
| | | | Бу пункт таләпләре тулысынча ук үтәлмәгән | 2,5 | | |
| | | | Бу пункт таләпләре үтәлмәгән | 0 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| сыйфаты <1> | эчке финанс аудиты федераль стандартлары таләпләренә туры килүе:<br>соответствие требованиям федеральных стандартов внутреннего финансового аудита:<br>1) аудиторлык чаралары үткәрү планының;<br>2) аудиторлык чаралары программаларының;<br>3) аудиторлык чараларын үткәрү нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрнең;<br>4)бюджет средстволары баш администраторының эшчәнлеге нәтиҗәләре турында еллык хисабының.<br>Ориентир булып бюджет средстволары баш администраторының Россия Федерациясе Бюджет кодексының $160^{2-1}$ статьясындагы 1 пунктында күздә тотылып, бюджет рискларын ачыклауга, бюджет рискларын минимальләштерү (юкка чыгару) һәм | | | | | чыгарыла.” |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | эчке финанс контрольлеген оештыру буенча чаралар җәһәтеннән тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр әзерләүгә юнәлдерелгән эшчәнлеге тора. | | | | | |

Министр Р.Р.Гайзатуллин